**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«10» 03 2020 ел Яр Чаллы № 741

Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләрен электрон бердәм исемле социаль йөртү билетлары (ташламалы транспорт картасы) буенча йөртүдән җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле алынмаган керемнәрне каплау максатында оешмаларга Тукай муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 6 сентябрендәге «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында» 887 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 10 мартындагы «2010 елда Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетында каралган субсидияләр һәм субвенцияләр бирү турында» 134 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 12 декабрендәге «2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 1141 номерлы карары нигезендә

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләрен электрон бердәм исемле социаль йөртү билетлары (ташламалы транспорт картасы) буенча йөртүдән җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле алынмаган керемнәрне каплау максатында оешмаларга Тукай муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга (1 нче кушымта).

2. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам .

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Г. Авзалов

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 10 03 741 номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләрен электрон бердәм исемле социаль йөртү билетлары (ташламалы транспорт картасы) буенча йөртүдән җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле алынмаган керемнәрне каплау максатында оешмаларга Тукай муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе**

Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә шәһәр һәм шәһәр яны даими муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы оешмаларга Тукай муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү процедурасын билгели.

1. Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләре өчен транспорт хезмәтләреннән бертигез файдалана алу мөмкинлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында бердәм айлык социаль йөртү билетын һәм балалар өчен бердәм айлык социаль йөртү билетын бирү тәртибен раслау турында» 2005 елның 7 апрелендәге 161 номерлы карары (алга таба - ТР Министрлар Кабинетының 2005 елның 7 апрелендәге 161 номерлы карары) нигезендә кертелгән бердәм айлык социаль йөртү билетларын һәм балалар өчен бердәм айлык социаль йөртү билетларын гамәлгә ашыру юлы белән тәэмин ителә.

2. Субсидияләр Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен электрон бердәм исемле социаль йөртү билетлары (ташламалы транспорт картасы) буенча гражданнарның аерым категорияләрен йөртүдән җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле алынмаган керемнәрне каплау максатында бирелә.

3. Субсидияләр агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетының җыелма бюджет язмасында бюджет чыгымнарын классификацияләүнең тиешле кодлары буенча Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга бирелә.

4. Тиешле финанс елына Тукай муниципаль районы бюджетында каралган субсидияләр Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориаль бүлегендә ачылган Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының шәхси счетында исәпкә алына.

5. Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен электрон бердәм исемле социаль йөртү билетлары (ташламалы транспорт картасы) буенча гражданнарның аерым категорияләрен йөртүдән җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле алынмаган керемнәрне каплауга субсидияләр алу өчен, субсидияләр алуга дәгъва итүчеләр яисә субсидия алу өчен гариза һәм документлар (алга таба - мөрәҗәгать итүчеләр) бирергә вәкаләтле башка затлар Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына түбәндәге документларны тапшыралар:

1) субсидия бирү турында гариза;

2) җитәкче вәкаләтләрен раслый торган документ;

3) Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашыру срогы килешү (шартнамә) төзү (яисә субсидия бирү турында карар кабул итү) планлаштырыла торган ай алдыннан килгән айның беренче числосына оешманың Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмавын раслаучы белешмәләр, бу субсидия алучының җитәкчесе һәм баш хисапчысы тарафыннан имзаланган документ һәм субсидия алучының мөһере (булганда) куелган документ белән раслана;

4) Тукай муниципаль районы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләре, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне кире кайтару буенча бурычның булмавын һәм Тукай муниципаль районы бюджеты алдында срогы чыккан башка бурычның булмавын раслаучы белешмәләр, бу субсидия алучының мөһере (булганда) куелган документ белән раслана.

6. Субсидияләр килешү (шартнамә) төзү (яисә субсидия бирү турында карар кабул итү) планлаштырыла торган ай алдыннан килүче айның беренче числосына түбәндәге критерийларга туры килергә тиеш булган оешмаларга бирелә:

- оешма Тукай муниципаль районында гомуми файдаланудагы транспортта пассажирлар йөртү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыра;

- оешманың Тукай муниципаль районында яшәүчеләрне йөртү өчен матди-техник чаралары бар;

- оешманың Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә үтәү вакыты җиткән бурычы булмаска тиеш;

- оешманың Тукай муниципаль районы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләре, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы һәм Тукай муниципаль районы бюджеты алдында срогы чыккан башка бурычлары булмаска тиеш;

- оешма үзгәртеп кору, ликвидацияләү процессында булырга тиеш түгел, аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, субсидия алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган;

- оешма чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында чит ил юридик затларының катнашуы өлеше (тулаем алганда, 50 проценттан артып киткән) булган, теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган Салым салуның ташламалы салым режимын бирә торган һәм (яки)

мондый юридик затларга карата финанс операцияләре (офшор зоналар) уздырганда мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмый торган дәүләт яисә территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган Россия юридик заты булырга тиеш түгел;

- оешма әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга башка муниципаль хокукый актлар нигезендә Тукай муниципаль районы бюджетыннан акча алмый.

7. Субсидия күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

**Ктр.орг. = ((SUM (Тiгор x Пi) + SUM (Тiпр x Рiпр)) - Втр.орг.**

Ктр.орг. - муниципаль районда гражданнарга юл йөрү билеты һәм балалар өчен юл йөрү билеты буенча транспорт хезмәтләре күрсәтүгә бәйле рәвештә транспорт оешмасы чыгымнарына Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсацияләр күләме;

i - транспорт оешмасында транспорт (автобус) төре;

Тiгор - законнар нигезендә транспортның i төре буенча билгеләнгән шәһәр эчендә пассажирлар йөртүгә гамәлдәге тариф;

Тiпр - законнар нигезендә муниципаль районда транспортның i төре буенча билгеләнгән шәһәр яны элемтәсендә пассажирлар йөртүгә гамәлдәге тариф;

Ташламалы транспорт кушымтасы булган электрон карта белән юл бәясен түләгәндә, траспортның i төре буенча 50 һәм аннан да күбрәк юл йөрүгә озак вакытлы файдаланудагы билетлар белән юл йөрүне түләү өчен Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты карары белән билгеләнгән тарифлар кулланыла.

Рiпр - шәһәр яны элемтәсендә АСОП операторы мәгълүматлары буенча башкарылган пассажир-километрлар саны;

Пi - транспорт оешмасы буенча хисап аендатранспортның i төрендә юл йөрү билетлары һәм балалар өчен юл йөрү билетлары буенча башкарылган юл йөрү саны. Юл йөрүне шәхсиләштерелгән исәпкә алу булганда - транзакцияләрнең факттагы саны;

Втр.орг. - АСОП операторы мәгълүматлары буенча транспорт оешмасының хисап ае өчен ташламалы транспорт карталарын һәм балалар өчен ташламалы транспорт карталарын сатудан алынган керемe.

Тукай муниципаль районының транспорт оешмалары арасында средстволарны бүлү, ташламалы транспорт картасы буенча гражданнарга транспорт хезмәтләре күрсәтүгә бәйле рәвештә, транспорт оешмалары тарафыннан субсидияләрне бүлү турында килешүгә кул кую юлы белән, ай саен 20 числодан да соңга калмыйча, хисап аенда ташламалы категория гражданнарның юл йөрү саны турында шәһәр пассажир транспортында йөрү өчен автоматлаштырылган түләү системасы операторы («Транспорт картасы» АЖ) тарафыннан бирелә торган хисап нигезендә башкарыла.

8. Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты тапшырылган документларны һәм исәп-хисапларны тикшерә, әлеге Тәртиптә билгеләнгәнчә субсидия бирү мөмкинлеге турында бәяләмә әзерли.

9. Субсидияләр бирү өчен нигез булып субсидия бирү мөмкинлеге турында бәяләмә һәм Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты һәм оешма арасында төзелә торган килешү (шартнамә) тора.

10. Субсидияләр Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан оешмаларның кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап счетларына күчерелә. Субсидияләрне күчерү срогы - Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән бәяләмә кабул ителгәннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча.

11. Субсидия бирүдән баш тарту турында карар түбәндәге очракта кабул ителә:

- субсидия алучы тарафыннан бирелгән документларның әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);
- субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы;
- оешманың әлеге Тәртиптә бәян ителгән критерийларга туры килмәве;
- әгәр Тукай муниципаль районы Советының бюджет турында карарындагы субсидия түләүгә каралган акчалар әлеге Тәртип нигезендә субсидия сыйфатында бирелгән булса.

12. Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты һәм муниципаль финанс контроле органы оешмалар тарафыннан субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне мәҗбүри тикшерә.

Субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен бозу очраклары ачыкланган очракта, субсидияләр Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының язмача таләбе буенча субсидия алучы тарафыннан, Тукай муниципаль районы бюджетына кире кайтару турында таләпләр алынганнан соң, 10 эш көненнән дә соңга калмыйча кире кайтарылырга тиеш. Субсидия билгеләнгән вакытка кайтарылмаган очракта, ул гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә Тукай муниципаль районы бюджеты кеременә түләтелә.